**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Казиле авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

2021 елның 29 апреле №19

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Иске Казиле авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Советы, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2021 нче елнын 26 нчы февралендэге № 02-06-2021/9 протестын карап, **карар** кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының 2017 елнын 19 нчы июнендэ 49 нчы номерлы карар белән расланган «Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре»нә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. I бүлектэге 6 пунктның 28 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-калдыкларны саклау һәм күмүне үз эченә алган калдыкларны урнаштыру, үз чиратында калдыкларны саклау, утильләштерү, йогышсызландыру, күмү максатларында, унбер айдан артык вакыт эчендә махсус объектларда калдыклар туплау буларак билгеләнде.»

2. III бүлектэге 19 пунктның 3 пунктчасын төшереп калдырырга;

3. III бүлектэге 19 пунктның 4 пунктчасын төшереп калдырырга;

4. III бүлекнең 39.4 пунктындагы «йорт чикләрендә яшел үсентеләрне тәртиптә тоту, куаклар һәм агачларны санитар кисүне үткәрү» сүзен тошереп калдырырга;

5. III бүлекнең 39.5 пунктын төшереп калдырырга;

6. III бүлекнең 39.9 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга..

3. Әлеге карар рәсми рэвештэ халыкка хәбәр ителгән (бастырып чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл жирлеге рэисе И.Х.Сагьдиев